ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

19.11.2021 Казан ш. № 317-71/кс-2021

«ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 № 119-12/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022-2023 елларга агынты суларны транспортлауга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2023 елларга «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 28.10.2020 № 119-12/кс-2020 карарына 1 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 № 119-12/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.11.2021 № 317-71/кс-2021карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» ҖЧҖ өчен 2021-2023 елларга агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «ТатСтройКа» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 2,84 | 2,92 | 2,92 | 3,04 | 3,04 | 3,06 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге